**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
27.08.2018

КАРАР
ПР-205

**Актаныш миниципаль районы башкарма комитеты административ комиссиясе тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану һәм аларны кичерү турындагы карарларны кабул итү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясенең Бюджет кодексының 47.2 маддәсе нигезендә, 2016 елның 6 маенда кабул ителгән 393 номерлы “Россия Федерациясе бюджет системасына түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану” Россия Федерациясе Хөкүмәте Карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының башкарма комитеты карар бирә:

1. Актаныш миниципаль районы башкарма комитеты административ комиссиясы тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану һәм аларны кичерү турындагы карарларны кабул итү тәртибен расларга (Кушымта).

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны финанс-бюджет палатасы рәисе К.Р.Каюмовага йокләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — Л.Р.Сираева

Сәлимов Д.З.
3-18-71

27.08.2018 ел № ПР-205

Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты карарына кушымта

**Административ комиссияләр тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына салынган административ штрафларны түләү буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану һәм аларны кичерү турындагы карарларны кабул итү тәртибе**

Актаныш муниципаль районы

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Муниципаль берәмлек бюджетына түләүләр (түләү буенча төп бурыч, пенилар, штрафлар) буенча бурычны түләттерүгә ышаныч юклыгын тану турында карар кабул итүнең әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип) муниципаль берәмлек бюджетына (алга таба – җирле бюджет) түләүләр буенча бурычны түләттерүгә ышаныч юклыгын тану очракларын, җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юклыгын тану турында карарлар кабул итү өчен нигезләрне раслаучы документлар исемлеген, һәм активлар керү һәм чыгу буенча комиссия (алга таба –Комиссия) эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм профессиональ чирләрдән мәҗбүри социаль иминләү турындагы Россия Федерациясе законнарында, Евразия икътисадый союзы хокукларында һәм Таможня эше турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән түләүләргә кагылмый.

1.3. Әлеге Тәртиптә җирле бюджетка түләүләр буенча бурычлар дигәндә административ комиссияләр тарафыннан салынган һәм җирле бюджетка үз вакытында түләнмәгән административ штрафлар аңлашыла. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану еллык исәп-хисапны төзер алдыннан инвентарьлаштыру үткәрү нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

1.4. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тануның инициаторы буларак җирле бюджетка керемнәрнең бюджетка түләүләрнең, алар буенча пенилар, штрафларның дөреслеген, тулылыгын, үз вакытында башкарылуын исәпкә алу һәм контрольдә тоту вазыйфалары йөкләнгән баш администраторы (алга таба – керемнәр администраторы) чыгыш ясый.

1.5. Керемнәр администраторы бурыч булу очрагын ачыклый, әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган документларны җыюны, рәсмиләштерүне гамәлгә ашыра һәм җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану турындагы мәсьәләне Комиссия каравына кертә.

1.6. Керемнәр администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә ышаныч юк дип тану турында карар кабул ителү турындагы акт

расланган көннән биш эш көне эчендә Россия Федерациясенең бухгалтерлык исәп-хисабы турындагы гамәлдәге законы нигезендә бурыч суммасын балансган төшерүне гамәлгә ашыра.

1.7. Керемнәр администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча салым булмаган керемнәр төрләре буенча кичерелгән бурычлар реестрын әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә алып бара.

## II. ҖИРЛЕ БЮДЖЕТКА ТҮЛӘҮЛӘР БУЕНЧА БУРЫЧЛАРНЫ ТҮЛӘТТЕРҮГӘ ЫШАНЫЧ ЮК ДИП ТАНУ ОЧРАКЛАРЫ

2.1. Бурычны түләттерүгә түбәндәге очракларда ышаныч юк дип таныла:

а) физик зат – административ штраф түләүче үлгәндә яки Россия Федерациясе гражданлык-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгәндә;

б) хосусый эшмәкәр – административ штраф түләүче “Бөлгенлеккә төшү турында (банкротлык) турында” 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле бюджетка түләүләр буенча бурычлы затның мөлкәте җитмәү сәбәпле түләнмәгән бурычлары өлешендә банкрот дип танылган очракта;

в) оешманың – административ штраф түләүченең оешма милкенең җитәрлек булмавы һәм (яки) әлеге оешманың гамәлгә куючылары (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләнелмәгән бурычы өчен бетерелүе очрагында;

г) бюджет керемнәре администраторының бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва бирү срогы) чыгу, шул исәптән җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызудан баш тарту турында суд тарафыннан билгеләмә чыгарылуга бәйле рәвештә, җирле бюджетка бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында суд акты;

д) суд приставы-башкаручы тарафыннан “Башкару производствосы турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерды Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешендә 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, түбәндәге очракларда, бюджетка түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан биш елдан күбрәк вакыт узганда:

бурыч күләме банкротлык турында эш буенча производство кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында Россия Федерациясе законында билгеләнгәнчә, бурыч күләме бурычлыга карата таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

бюджетка түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә средстволарның булмавы сәбәпле банкротлык турында эш производствосы туктатылганда.

2.2. Әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган очраклардан тыш, үз вакытында түләнмәгән административ штрафлар, Административ хокук бозулар турында

Россия Федерациясе кодексында административ җәза билгеләнү турындагы карарны башкару өчен каралган срок чыгу очрагында, мондый срокны өзү, туктатып тору яки озайту турындагы нигезләр булмаган очракта, түләттерелүләре өметсез дип танылалар.

## III. ҖИРЛЕ БЮДЖЕТКА ТҮЛӘҮЛӘР БУЕНЧА БУРЫЧНЫ ТҮЛӘТТЕРҮГӘ ЫШАНЫЧ ЮКЛЫГЫН ТАНУ ҺӘМ АНЫ КИЧЕРҮ ТУРЫНДАГЫ КАРАРЛАРНЫ КАБУЛ ИТҮ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР БУЛУЫН РАСЛАУЧЫ ДОКУМЕНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

3.1. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерүгә ышаныч юклыгын тану турындагы карарны кабул итү өчен нигез булуны дәлилләүче документлар булып торалар:

а) инвентарьлаштыру нәтиҗәләре турындагы акт (ф. 0504835, “Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, дәүләтнең бюджеттан тыш фондлары белән идарә органнары, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кабул ителгән беренче исәпкә алу документлары һәм бухгалтерлык исәп-хисаплары регистрлары формаларын һәм аларны куллану буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” Россия Финанс министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 52н номерлы боерыгы белән (алга таба - Россия Финанс министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 52н номерлы боерыгы) расланган);

б) кергән акчаларны исәпләү буенча инвентарьләштерү язулары (ф. 0504091, Россия Финанслар министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 52н номерлы боерыгы белән расланган);

в) керемнәр администраторы хисапларыннан җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларның исәпкә алынган суммасы турындагы өземтә, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта формасы буенча;

г) керемнәр администраторыннан җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында белешмә;

д) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерүнең өметсез булуын тану очракларын раслаучы документлар:

физик затның – җирле бюджетка түләүләрне гамәлгә ашырырга тиешле затның үлемен раслый торган яки аны үлгән дип тану фактын раслый торган документ;

җирле бюджетка административ штраф түләүче хосусый эшмәкәрнең банкрот дип танылуына бәйле рәвештә эшчәнлегенең туктатылуы турында Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан, оешма – җирле бюджетка администартив штраф түләүченең бетерелүенә бәйле рәвештә эшчәнлеген туктатуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә мәгълүматларны эченә алган документ;

бюджет керемнәре администраторының бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва бирү срогы) чыгу, шул исәптән җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза тапшыруның кулдан ычкындырылган срогын торгызу турында суд тарафыннан билгеләмә чыгарылуга бәйле рәвештә, җирле бюджетка бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында суд акты;

суд приставы-башкаручының “Башкару производствосы турында” 2007 елның

2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешендә 3 һәм 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында чыгарылган карары.

## IV. АКТИВЛАР КЕРҮ ҺӘМ ЧЫГУ БУЕНЧА КОМИССИЯ ҺӘМ ҖИРЛЕ БЮДЖЕТКА ТҮЛӘҮЛӘР БУЕНЧА БУРЫЧНЫ ТҮЛӘТТЕРҮГӘ ЫШАНЫЧ ЮКЛЫГЫН ТАНУ ҺӘМ АНЫ КИЧЕРҮ ТУРЫНДАГЫ КАРАРЛАРНЫ ӘЗЕРЛӘҮ МАКСАТЫННАН АНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДАГЫ НИГЕЗЛӘМӘ

4.1. Комиссия составы керемнәр администраторы тарафыннан даими нигездә раслана.

4.2. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, комиссия секретареннан һәм Комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссия эшчәнлеге белән Комиссия рәисе, ул булмаган очракта – рәис урынбасары идарә итә.

4.3. Комиссия утырышы кирәк булган очракларда уздырыла.

4.4. Комиссия утырышы, әгәр дә анда әгъзаларның гомуми саныннан өчтән ике өлешеннән ким булмаган сандагы кешеләр катнаша икән, узган булып санала. Комиссия карары Комиссия әгъзаларының күпчелек ачык тавыш бирүләре саны буенча беркетмә формасында кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта хәлиткеч тавышка Комиссия рәисе ия була.

4.5. Комиссия утырышы беркетмәсе рәислек итүче һәм комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.6. Комиссия 10 көн дәвамында керемнәр администраторы тарафыннан тәкъдим ителгән документлар исемлеген Тәртипнең 10 пункты нигезендә карый һәм җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерүгә ышаныч юклыгы һәм аны кичерү турындагы карар проектын әзерли.

4.7. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерүгә ышаныч юклыгы турындагы карар түбәндәгеләрне үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә (3 нче кушымта):

а) оешманың тулы атамасы (физик затның фамилиясе, исеме, этисенең исеме);

б) салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, оешманың салым түләүчесен учетка кую сәбәпләре коды (физик затның салым түләүчесенең идентификация номеры);

в) бурыч китереп чыгарган штраф турында мәгълүматлар;

г) бюджетка түләүләр буенча бурычны исәпкә алуда кулланыла торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәренең классификациясе коды, аның атамасы;

д) җирле бюджетка түләүләр буенча барлыкка килгән бурыч суммасы;

е) бюджетка административ штраф түләү буенча бурычны түләтүгә ышанычның юклыгын тану турында карар кабул итү датасы;

ж) комиссия әгъзалары имзасы.

4.8. җирле бюджетка административ штраф түләү буенча бурычны түләттерүгә ышаныч юклыгын тану һәм аны кичерү турында Комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән акт керемнәр администраторы җитәкчесе тарафыннан раслана.

Муниципаль берәмлек бюджетына
түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә
ышаныч юк дип тану һәм аларны кичерү
турында карар кабул итү тәртибенә
1 нче кушымта

______________________

Муниципаль берәмлек бюджетына
салым булмаган керемнәр төрләрендәге ______________________ түләүләр буенча
_______ ел өчен

______________________
(керемнәр администраторы)

кичерелгән бурычлар
РЕЕСТРЫ

(сум.)

| № п/п | Бурычны түләттерүгә ышаныч юк дип тану өчен нигез | Оешманың исеме (ИНН/КПП), физик затның Ф.И.Ә.и. (булган очракта, ИНН) | Түләү төре | Түләү буенча бурыч барлыкка килү срогы | Кичерелгән бурыч суммасы, барлыгы | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Төп бурыч | Пенилар | Штрафлар |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | | | |

Җитәкче ______________ ______________________

М.У. (имза) (Ф.И.О.)

Муниципаль берәмлек бюджетына
түләүләр буенча бурычларны түләттерүгә
ышаныч юк дип тану һәм аларны кичерү
турында карар кабул итү тәртибенә
2 нче кушымта
___________________________________

Исәп-хисаплардан
_________________________________________________
(керемнәр администраторы)
муниципаль берәмлек бюджетына
түләүләр буенча бурычларның исәпкә алынган суммасы
_________________________________

____________________________________________________
(оешманың исеме (ИНН/КПП),
физик затның Ф.И.Ә.и., (булган очракта ИНН)
_______________елга торышта
турындагы
ӨЗЕМТӘ

(сум.)

| № п/п | Түләү төре | Түләү буенча бурыч барлыкка килү срогы | Түләү буенча барлык бурыч | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Төп бурыч | Пенилар | Штрафлар |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | |

Җитәкче _______________ _________________________
М.У. (имза) (Ф.И.Ә.и.)

Муниципаль берəмлек бюджетына
түлəүлəр буенча бурычларны түлəттерүгə
ышаныч юк дип тану һəм аларны кичерү
турында карар кабул итү тəртибенə
3 нче кушымта

Бюджетка түлəүлəр буенча бурычны түлəттерүгə ышаныч булмавын тану һəм аны кичерү турында
АКТ

от «____» _______________ 20__ г. № ____

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(оешманың тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, əтисенең исеме)

___________________________________________________________________________

(ИНН, ОГРН, КПП)

Аның буенча бурыч барлыкка килгəн түлəү турындагы мəгълүматлар ___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(КДБ һəм аның тулы исеме)

Бурыч суммасы ___________ сум _____ тиен.

Түбəндəгелəр нигезендə ___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(реквизитлары күрсəтелгəн конкрет документлар күрсəтелə)

Комиссия рəисе ______________________/______________/__________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.Ə.и.)

Комиссия əгъзалары:

_____________________________/______________/_______________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.Ə.и.)

______________________________________________/______________/________________
_

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.Ə.и.)